ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Түбән Баланда авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

2019 елның 1 декабре № 10

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Кәкре Күл авыл җирлеге Түбән Баланда авылында гражданнар җыены нигезендә
Карар:
1. 2020 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре Күл авыл җирлегенең Түбән Баланда авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, (I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлар) 500 сум күләмендә үзсалым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
**- Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру**
Түбән Баланда авылы урамнарын яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу,
Түбән Баланда авылында кырларны чабу эшләре.
**- Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру**
Түбән Баланда авылында тирән насос, суүткәргечне ремонтлау һәм алыштыру.
**- Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**
Түбән Баланда авылының Яңа, Чапаев, Терешкова, Ленин урамнарына ком һәм вак таш (ЩПС)
Түбән Баланда авылында кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту.
3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы
ТР Аксубай муниципаль районы С.С. Елисеев